**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Багряжского сельского**
**поселения Заинского**
**муниципального района**

ул. Центральная, д.47а с. Средний
Багряж, Заинский район, 423516

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Баграж авыл җирлегенең**
**башкарма комитеты**

Үзәк урам, 47а йорт, Түбән
Баграж авылы, Зәй районы, 423516

Телефон, факс 64-3-42. Электронный адрес: Bagr.zai@tatar.ru, сайт: www.Bagrazh.moy.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**07.02.2023** **№ 4**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2019 елның 20 июнендәге 24 номерлы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 339-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2019 елның 20 июнендәге 24 нче номерлы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган (Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 10 декабрендәге 42 номерлы, 2020 елның 12 августында 18 номерлы, 2020 елның 26 октябрендәге 20 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.1 пунктына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Түбәндәге эчтәлекле 14 пунктны өстәргә:

«14) нотариаль таныкланган килешүләрнең эчтәлеген белдерә торган документларның дубликатларын бирергә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
җитәкчесе П.Н. Минеев